**СОВЕТ ЯМАШУРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422735, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Ямашурма, ул. Советская,5

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯМАШИРМӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422735, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Ямаширмә авылы, Совет ур., 5

Тел./факс: +7(84365) 777-02, e-mail: Yamash.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**19 ноябрь 2020 ел** **№ 11**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге Советының 2019 елның 08 ноябрендәге 138 нче номерлы карары белән расланган Ямаширмә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында, 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон Федераль законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Ямаширмә авыл җирлеге Советының 2019 елның 08 ноябрендәге 138 нче номерлы (Советның 07.02.2020 № 152 карары редакциясендә) карары белән расланган, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ямаширмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә, 14 статьяның 3 пунктындагы 4 пунктчада «хезмәт кенәгәсен» сүзләреннән соң «һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр» сүзләрен өстәп үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Ф.К.Мухтаров